| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 27 ноябрь г.Казань № 984

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 921 нче карары белән расланган Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 921 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, 186 нчы, 2022 ел, 21 ноябрь, 1238 нче, 2022 ел, 2 декабрь, 1279 нчы, 2023 ел, 20 март, 297 нче, 2023 ел, 18 июль, 861 нче, 2023 ел, 27 сентябрь, 1190 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Контроль объектын билгеле бер куркыныч категориясенә кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне (функцияләр башкаруны) тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системалары турында” 2011 елның 24 октябрендәге 861 номерлы карары белән расланган «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль

дәүләт мәгълүмат системасын алып бару кагыйдәләренә 1 нче кушымтада китерелгән Федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге), төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төрләренең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре нигезендә Дәүләт комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

22 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Консультациягә язылу «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша башкарылырга мөмкин».»;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Профилактик визит контрольдә тотыла торган зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча вазыйфаи зат тарафыннан кисәтү әңгәмәсе рәвешендә йә «Инспектор» видео-конференция-элемтә яисә мобиль кушымтасыннан файдалану юлы белән уздырыла.

Профилактик визит барышында контрольдә тотылучы затка аның эшчәнлегенә яисә аның карамагындагы контроль объектларына карата куела торган мәҗбүри таләпләр, аларның куркыныч критерийларына туры килүе турында, куркыныч категориясен киметү буенча тәкъдим ителә торган ысуллар турында, тиешле куркыныч категориясенә кертелүенә карап, контроль объектына карата үткәрелә торган контроль чаралары төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы турында мәгълүмат бирелә, ә вазыйфаи зат контроль объекты белән таныша, контроль объектларын куркыныч категорияләренә кертү өчен кирәкле мәгълүмат җыя һәм контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлү дәрәҗәсен бәяли.

Профилактик визит контроль (күзәтчелек) органы инициативасы буенча (мәҗбүри профилактик визит) яки контрольдә тотылучы зат инициативасы буенча үткәрелә.»;

25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. Мәҗбүри профилактик визит Контроль (күзәтчелек) турында Федераль законның 521 статьясы нигезендә уздырыла.»;

26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26. Контрольдә тотыла торган зат инициативасы буенча профилактик визит Контроль (күзәтчелек) турында Федераль законның $52^2$ статьясы нигезендә уздырыла.»;

30 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30. Билгеле бер куркыныч категорияләренә кертелгән контроль объектларына карата планлы контроль (күзәтчелек) чараларының төрләре, үткәрү ешлыгы, мәҗбүри профилактик визитларны үткәрү ешлыгы зыян (зарар) китерү куркынычларына пропорциональ рәвештә билгеләнә.

Планлы контроль (күзәтчелек) чараларының үткәрү ешлыгы һәм мәҗбүри профилактик визитларның үткәрү ешлыгы түбәндәгечә билгеләнә:

а) ике елга бер планлы контроль (күзәтчелек) чарасы йә елына бер мәҗбүри профилактик визит - югары куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектлары өчен;

б) уртача куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән ешлык белән мәҗбүри профилактик визитлар үткәрү.»;

33 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33. Дәүләт комитеты тарафыннан түбәндәге планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелә:

а) документларны тикшерү;

б) күчмә тикшерү.»;

38 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Күчмә тикшерү дистанцион үзара хезмәттәшлек чараларыннан, шул исәптән видеоконференция элемтәсе аша, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»;

43 пунктта:

татарча текста «бозулар» сүзенә кадәр «мәҗбүри таләпләрне» сүзләрен өстәргә;

«үтәү» сүзен «бетерү» сүзенә алмаштырырга;

45 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«45. Дәүләт комитетының күрсәтмәсенә шикаять контрольдә тотылган зат күрсәтмәне алган көннән башлап 10 эш көне эчендә бирелергә мөмкин.

Судка кадәр бирелгән шикаять, судка кадәр шикаять бирү системасында теркәлгән көннән башлап 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, аны карау вәкаләтенә ия булган вазыйфаи зат тарафыннан каралырга тиеш.

Контроль объектын куркыныч категориясенә кертү турындагы карарга шикаятьне карау Дәүләт комитеты тарафыннан шикаять кергән көннән алып биш эш көненнән артмаган вакытта гамәлгә ашырыла.

Шикаять бирү срогын узу мөрәҗәгать итүчене, срокны үткәрүнең җитди сәбәпләре булганда, шикаять белән мөрәҗәгать итү хокукыннан мәхрүм итми. Уздырылган срокны торгызу турындагы үтенеч шикаять белән бергә бирелә.

Шикаять биргән зат, шикаять буенча карар кабул ителгәнче, аны кире алырга мөмкин. Бу очракта шул ук нигезләр буенча шикаятьне кабат җибәрү рөхсәт ителми.

Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) тарафыннан карала.

Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан карала.»;

46 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин